ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№_102_ от «_25__» ___10____ 2016

Муниципаль район башлыгының
2014 елның 27 гыйнварындагы
008 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы РФ Президенты Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын һәм муниципаль хокукый актларын кабул иткәндә һәм гамәлгә ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карары, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә иҗтимагый советлар оештыру турында» 2009 елның 16 апрелендәге семинар-киңәшмә резолюциясе, ТР Министрлар Кабинетының «аерым оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру чаралары турында»2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, к а р а р б и р ә м :

1. Район Башлыгының 2014 елның 27 гыйнварында 008 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә: «Иҗтимагый совет сыйфатны бәйсез бәяләүне аңа йөкләнгән бурычлар чикләрендә гамәлгә ашырган очракта:

   - сыйфатка бәйсез бәя бирү үткәрелүче оешмаларның (учреждениеләрнең) исемлеген билгели;

- югарыда күрсәтелгән оешмалар (алга таба - оператор) тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турында мәгълүматны җыюны, гомумиләштерүне һәм анализлауны гамәлгә ашыручы оешма өчен техник бирем эшләү өчен тәкъдимнәр төзи, эшләр, хезмәтләр закупкалары документациясе проектларын, шулай ук оператор белән төзелә торган муниципаль контрактлар проектларын карауда катнаша;

- кирәк булганда оешмалар хезмәт күрсәтүләрен бәяләү һәм аның сыйфаты критерийларын билгели (федераль законнарда билгеләнгән гомуми критерийларга өстәмә рәвештә);

- иҗтимагый фикерне ачыклау, гомумиләштерү һәм анализлау, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, һөнәри берлекләр һәм башка экспертлар тарафыннан төзелгән рейтингларын төзү эшен оештыра;

- Оешмаларның сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм тиешле эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр җибәрә.».

1.2. “Иҗтимагый совет рәисе” бүлекчәсенең 4 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

- Мамадыш муниципаль районы Советы Рәисенең иҗтимагый түләүсез нигездә ярдәмчесе булып тора.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе В.Н.Фәизовка йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы вазифаларын
башкаручы И.Э.Фәттахов